| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Бима авылы № 14-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип таныйрга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2014 елның 17 октябрендәге 35-1 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2014 елның 17октябрендәге 35-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августынын 11-2 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 12 апрелендагы 12-3 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 16 августындагы 11-3 номерлы карары 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Э.И.Михайлов